# КАРАР

## Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**08 апрель 2024ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 8 апрлендә узган: «2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толкалган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Төрнәс авылы юлларын сезонлы карап тоту);

Төрнәс авылының урам утлары җиһазларын көйләү ;

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважиналарны лицензияләү, Төрнәс авылында су белән тәэмин итү системаларын агымдагы ремонтлау);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү өчен су саклау савытын сатып алу);

торак пункт территориясен төзекләндерү (Төрнәс авылында Садовая, Школьная, Центральная урамнары) мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 765 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 408 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 229 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 179 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Төрнәс авылы юлларын сезонлы карап тоту);

Төрнәс авылының урам утлары җиһазларын көйләү;

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважиналарны лицензияләү, Төрнәс авылында су белән тәэмин итү системаларын агымдагы ремонтлау);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү өчен су саклау савытын сатып алу);

торак пункт территориясен төзекләндерү (Төрнәс авылында Садовая, Школьная, Центральная урамнары) мәсьәләләре буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: С.В. Белов

Төрнәс авыл җирлеге башлыгы С.В.Белов